Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Кече Аксубай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

2019 елның 27 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 нче статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " №111 карары нигезендә 2019 елның 27 ноябрендә "Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне:

1) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- су белән тәэмин итү өчен тирәнгә куела торган насос сатып алу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау;
хәл итүгә җибүгә юнәлдерүгә килешәсезме?

ӘЙЕ ЮК"

соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 47 гражданин кертелгән, тавыш бирүдә катнашучылар саны 28 гражданин.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- "әйе» позициясе өчен 28 граждан тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Кече Аксубай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2"Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне:

1) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- су белән тәэмин итү өчен тирәнгә куела торган насос сатып алу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау;
хәл итүгә җибүгә юнәлдерүгә килешәсезме?"
соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Аксубай
авыл җирлеге башлыгы М. М. Сөләйманкин